Республика Татарстан Совет Александровского сельского поселения Сармановского муниципального района	Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ
19 февраля 2026г

КАРАР
№ 17

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Сарман муниципаль районының 10.11.2014 № 21 авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Александровское сельское поселение» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге советы карар кылды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 декабрендәге 21 номерлы карарына (карарлар редакциясендә 29.05.2015 N 15, 19.06.2018 N 83, 20.11.2018 N 104, 20.02.2020 N 149, 01.11.2024 N 110, 22.11.2024 N 113А, 15.12.2025 № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2 пунктның 2.5 пунктчасында «, билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе
Александровка авыл җирлеге
Сарман муниципаль районының И.Ф. Вафин